ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 9 октябре
№ 81-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Законлылык һәм хокук
тәртибе комитеты
тарафыннан
кертелә

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1– 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш ), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш ), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024 № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә гражданнарга – өч мең сумнан дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – егерме биш меңнән алып кырык мең сумга кадәр; юридик затларга – йөз меңнән ике йөз илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына яисә кисәтү ясала.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – дүрт мең сумнан биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык мең сумнан алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга – биш йөз мең сумнан алып бер миллион сумга кадәр административ штраф салына.»;

в) 3 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә гражданнарга – өч мең биш йөз сумнан дүрт мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз биш меңнән кырык биш мең сумга кадәр; юридик затларга – өч йөз меңнән алып дүрт йөз илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

г) 4 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – дүрт мең биш йөз сумнан биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык биш меңнән илле мең сумга кадәр; юридик затларга – алты йөз меңнән алып бер миллион сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 3.16 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3.16 статья. Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибен бозу;**

б) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләүле муниципаль парковкалардан (парковкадагы урыннардан) файдалануның муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртибен бозган өчен, ул түләүле муниципаль парковкага (парковкадагы урынга) транспорт чарасын куйган өчен түләмәүдә, йә муниципаль хокукый актта билгеләнгән күләмнән азрак түләүдә, йә парковкадан файдаланган өчен муниципаль хокукый актта билгеләнгән түләү срогыннан соңрак түләү кертүдә чагыла, – ».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларында үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) тиешле булмаган урыннарда халык күңел ачуга бәйле рәвештә урам сәүдәсен оештыру һәм хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтүгә, шулай ук түләүле муниципаль парковкада (парковкадагы урында) транспорт чараларын куйган өчен җаваплылык каралган норманы камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Закон проектының 1 статьясындагы 1 пункты тиешле булмаган урыннарда халык күңел ачуга бәйле рәвештә урам сәүдәсен оештыру һәм хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтүгә (ТР КоАП 3.2 статьясы). Әлеге хокук бозуларны кылган өчен гамәлдәге штраф санкцияләре бик аз, шуңа күрә аларны куллану хокук бозучыларга алга таба мондый хокук бозуларны кабат кылмаска этәрми. Закон проектында тәкъдим ителгәнчә, гражданнар өчен максималь штрафлар биш мең сум, вазыйфаи затлар өчен – илле мең сум, юридик затлар өчен – бер миллион сум тәшкил итәчәк.

Шулай ук закон проекты белән муниципаль парковкалардан түләүле файдалану тәртибен нәтиҗәлерәк хокукый җайга салу максатларында законның «Түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) транспорт чараларын урнаштырган өчен түләмәү» турындагы 3.16 статьясына үзгәрешләр кертелә.

Закон проектында булган үзгәрешләрне кертүгә, гражданнарны Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының күрсәтелгән статьясы буенча административ хокук бозулар кылган өчен җаваплылыкка тарту турындагы эшләрне караганда барлыкка килә торган тискәре суд практикасы сәбәп булды.

Аерым алганда, судлар, Казан шәһәренең Административ комиссиясе карарын гамәлдән чыгарып, җәлеп ителүче затлар гамәлләрендә административ хокук бозу составы булмауга сылтама ясый, транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкада беренче 15 минут тәмамланганнан соң тоту өчен парковка өчен түләү башкарылырга тиеш. Судлар Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.16 статьясында түләүле муниципаль парковкадан файдалануга түләүнең үз вакытында булмавын күрсәтә.

Түләүле муниципаль парковкалардан файдаланган өчен түләү тәртибе Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалардан (парковкадагы урыннардан) файдалану һәм аларда транспорт чараларын урнаштыру кагыйдәләре белән расланган («Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан муниципаль

парковкалар төзү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2014 елның 30 декабрендәге 7660 номерлы карары).

Күрсәтелгән актта парковка өчен парковкадан файдалануның беренче 15 минутында түләнергә тиеш дип билгеләнгән.

Шулай итеп, югарыда күрсәтелгән хокуксыз гамәлләр өчен җаваплылык булмау сәбәпле, түләүле муниципаль парковкада транспорт чараларын урнаштыручы затлар, үзләренең җәзасызлыгын аңлап, машиналарны чикләнмәгән күләмдә калдыралар, парковкадан файдаланган өчен тулысынча түләмиләр.

Шуның белән гражданнарның түләүле муниципаль парковкада транспорт чарасын куюда намуслы һәм закон тыңлаучан гражданнарның хокуклары чикләнә.

Югарыда бәян ителгән закон проекты белән Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.16 статьясына үзгәрешләр кертелә, алар түләүле муниципаль парковкаларда (парковкадагы урыннарда) транспорт чарасын куйган өчен түләмәүдә чагылган яисә муниципаль хокукый актта билгеләнгән суммадан кимрәк күләмдә түләү кертүдә, йә парковкада билгеләнгән парковкадан файдаланган өчен түләү срогыннан соңрак түләгән өчен җаваплылыкны күздә тота.

Закон проекты 2 статьядан тора.

2 статья Татарстан Республикасы Законының рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керүен күздә тота.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.